**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 16 ноябрь № 858

г. Казань

Коммерциягә карамаган оешмаларга «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыру һәм үткәрү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә, шулай ук «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыру һәм үткәрү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу декарарга теркәлгән Коммерциягә карамаган оешмаларга «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыру һәм үткәрү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\858.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 16 ноябрь, 858 нче
карары белән расланды

Коммерциягә карамаган оешмаларга «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыру һәм үткәрү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм коммерциягә карамаган оешмаларга «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыру һәм үткәрү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү механизмын билгели.

2. Субсидия әлеге Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына билгеләнгән тәртиптә күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Субсидияләр түбәндәге шартларга җавап биргән, дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган, коммерциягә карамаган оешмаларга бирелә:

законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән булу һәм эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру;

үзгәртеп оештыру, ябылу яки банкротлык стадиясендә булмау;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына һәм дәүләт бюджеттан тыш фондка мәҗбүри түләүләр буенча кредиторлык бурычлары булмау (билгеләнгән тәртиптә бурычның структурасын үзгәртү турында килешү төзегән, бурыч түләү графикларын үтәгән һәм агымдагы түләүләрне үз вакытында гамәлгә ашырган субъектлардан тыш);

субсидия бирүгә гариза (алга таба – гариза) керткән вакытка Татарстан Республикасы буенча хезмәткә яраклы халык өчен билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән азрак булмаган уртача эш хакы дәрәҗәсен тоту;

элегрәк бирелгән бюджет акчасыннан максатчан һәм (яки) нәтиҗәле файдаланмауны булдырмау;

уңай имидж булдыруга, халык арасында танылуга һәм үзебезнең илнең иң яхшы менеджерлары – предприятиеләр (оешмалар) җитәкчеләре, сәнәгатьчеләр, эшмәкәрләр тәҗрибәсе белән бүлешүгә булышлык күрсәткән чаралар оештыру һәм үткәрү тәҗрибәсе булу.

4. Субсидия алу өчен, коммерциягә карамаган оешмалар Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба – Вәкаләтле орган) түбәндәге документларны кертә:

Вәкаләтле орган раслаган форма буенча гариза;

гамәлгә кую документлары күчермәләре;

җитәкче вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләре;

финанс-икътисадый нигезләмә белән «Ел җитәкчесе» республика иҗтимагый конкурсын оештыруга һәм үткәрүгә чыгымнар сметасы;

уңай имидж булдыруга, халык арасында танылуга һәм үзебезнең илнең иң яхшы менеджерлары – предприятиеләр (оешмалар) җитәкчеләре, сәнәгатьчеләр,

эшмәкәрләр тәҗрибәсе белән бүлешүгә булышлык күрсәткән чаралар оештыру һәм үткәрү тәҗрибәсе турында мәгълүмат.

5. Коммерциягә карамаган оешмалар үз ихтыярлары буенча Вәкаләтле органга түбәндәге документларны кертергә хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында шаһәдәтнамә күчермәсе;

салым органында исәпкә кую турында шаһәдәтнамә күчермәсе;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләр буенча кредиторлык бурычлары булмауны раслый торган документ.

6. Коммерциягә карамаган оешма бу Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән документларны кертмәгән очракта, Вәкаләтле орган әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

7. Вәкаләтле орган:

кертелгән көнне гаризаларны бит саннары куелган, беркетелгән һәм мөһер белән расланган булырга тиешле журналда терки;

гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә гариза бирүченең әлеге Тәртипнең 3 нче пунктында куелган таләпләргә туры килү-килмәвен билгели һәм кертелгән документларны бу Тәртипнең 4 нче пункты нигезендә карап тикшерә;

гариза бирүче һәм кертелгән документлар әлеге Тәртипнең 3 нче һәм 4 нче пунктларына туры килгән очракта, бу пунктның өченче абзацында билгеләнгән вакыт чыкканнан соң бер эш көне эчендә юридик затка субсидия бирү турында карар кабул итә.

8. Әлеге Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган комплектын кертү, шулай ук гариза бирүченең әлеге Тәртипнең 3 нче пунктында куелган таләпләргә туры килмәве субсидия бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

9. Субсидия бирү аңа карата субсидия бирү турында карар кабул ителгән коммерциягә карамаган оешма (алга таба – субсидия алучы) һәм Вәкаләтле орган арасында төзелгән субсидия бирү турындагы килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Килешү билгеләнгән тәртиптә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән ике эш көне эчендә төзелә.

Субсидия бирү турындагы килешү формасы Вәкаләтле орган тарафыннан раслана.

Килешүдә субсидиянең күләме, максатчан билгеләнеше, чараларны оештыру һәм үткәрүгә бәйле чыгымнар төрләре, субсидиядән файдалану турында хисап кертү тәртибе һәм вакытлары, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләрнең агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан кире кайтарылу очраклары һәм тәртибе, субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә, субсидия алучының бу Тәртипнең һәм төзелә торган килешүнең шартларын үтәү турындагы нигезләмәне үтәвенә Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан тикшерүләр үткәрүгә субсидия алучының ризалыгы күздә тотыла.

10. Вәкаләтле орган һәм субсидия алучы арасында субсидия бирү турында килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ун көн эчендә Вәкаләтле орган субсидия алучының кредит оешмасында ачылган хисап исәпләренә

субсидияне күчерә.

11. Субсидия алучы Вәкаләтле органга субсидия бирү турындагы килешүдә күздә тотылган форма нигезендә һәм тәртиптә субсидиядән файдалану турында хисап кертә.

12. Субсидияләр Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә түбәндәге очракларда субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарып бирелергә тиеш:

субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар керткәндә;

билгеләнгән вакытта субсидиядән файдалану турында хисап кертмәгәндә;

субсидия акчасыннан максатчан файдаланмаганда.

13. Субсидия бирү турындагы килешү белән күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә субсидия алучы тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

14. Субсидия алучы әлеге Тәртипнең 12 нче һәм 13 нче пунктларында күрсәтелгән субсидияне кайтару вакытларын бозган очракта, Вәкаләтле орган субсидияне кайтару вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча законнар белән билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.

15. Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидия алучыларның субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүләрен тикшерүне законнар белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

16. Субсидиядән максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту Вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---